**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты Транспорт корылмалары институтының автомобиль юллары, күперләр һәм тоннельләр кафедрасы доценты Мәүлиев Ленар Фидаис улына – Татарстан Республикасында җирле арзан бәяле нык минерал чималдан һәм сәнәгать калдыкларыннан юл төзү технологияләрен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты Төзелеш институтының төзелеш өлкәсендә җитештерү технологияләре кафедрасы доценты – Мөхәммәтрәхимов Рөстәм Хәниф улына – төзелештә аддитив җитештерү өчен яңа композиция материалларын һәм модификацияләнгән дисперсия-армирланган бетоннарны өйрәнүгә һәм эшләүгә зур өлеш кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыятенең тәҗрибә-конструкторлык бюросы исәпләүләр бүлеге инженер-конструкторы Сафиуллин Айрат Фәнил улына – очу аппаратларын аварияле хәлдә су өстенә утыртырга мәҗбүр булганда пассажирларның һәм экипажның исән калуын һәм җәрәхәтләнмәвен тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казан, Кремль
2019 ел, 15 июнь
№ ПУ-351